ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2019 п.г.т.Алексеевское № 37

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**3нче “Әтәчкәй” Алексеевск балалар бакчасы**
**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү**
**учреждениесе Уставына**
**үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында”гы6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 29 декабрь, 2012 ел, 273-ФЗ санлы Федеральзакон нигезендә һәм оештыру документларына туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 3 нче “Әтәчкәй” Алексеевск балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү

учреждениесеУставындагы “Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе фәне, эшчәнлек максатлары, эшчәнлек төрләре”нең 2 нче бүлеге, 2.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“2.6. Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирүучреждениесе муниципаль биремнән тыш билгеләнгән эшләрне үтәргә, эшчәнлек төрләренә кагылышлы хезмәтләр күрсәтергә хокуклы, физик һәм юридик затлар өчен бер үк хезмәтләрне күрсәткәндәбер үк акчага һәм шартларда. Күрсәтелгән түләүне билгеләү тәртибен оештыручы билгели.

Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтергә хокуклы. Эшчәнлекнең әлеге төре муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җирле норматив акты белән регламентлаштырылган.

2.6.1. Конкурслар, чаралар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре оештырып үткәрү эшчәнлеге.

2.6.2.Сәхнәләштерелгән әсәрләр, концертлар һәм башка сәхнәләштерелгән чыгышлар оештырып куюэшчәнлеге.

2.6.3. Педагог-психологның шәхси консультацияләре.

2.6.4. Педагог-логопедның шәхси консультацияләре.

2.6.5.Баланың психик үсешенә төзәтмәләр кертү буенча педагог-психологныңшәхси дәресләре.

2.6.6. Баланың сөйләм теле үсешенә төзәтмәләр кертү буенча педагог-логопед белән шәхси дәресләр үткәрүе.

2.6.7.Баланың психик үсешенә төзәтмәләр кертү буенча педагог-психологның төркем белән дәресләр үткәрүе.

2.6.8. Баланың сөйләм теле үсешенә төзәтмәләр кертү буенча педагог-логопедның төркем белән дәресләр үткәрүе.

2.6.9. Балаларның буш вакытларын оештыру.

2.6.10. Шәхси күчемсез милекне арендага тапшыру.

2.6.11. Китаплар бастыру эшчәнлеге (укыту-методикәсбаплар бастыру).

2.6.12. Фотография өлкәсендәге эшчәнлек.

2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 3нче “Әтәчкәй” Алексеевск балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдирәсенә (Л.Ю.Матвеева) вәкаләтле дәүләт органында оештыру документларында үзгәрешләрне дәүләт теркәве буенча вәкаләтләр бирергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүнесоциаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.П.Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**